ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2016 Казан ш. № 10-9/кс

2016 – 2019 елларга «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя куюю нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы карарына, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәлмәләрне исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2011 елның 15 февралендәге 47 санлы Россия Федерациясенең региональ үсеш министрлыгы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 елның 1 октябреннән 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе җитештерү

программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.

4. «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесенә билгеләнгән вакытка, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2016 елның 12 февралендәге 35а санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
26.08.2016 № 10-9/кс
1 карарына кушымта

2016 – 2019 елларга
«Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан билгеле бер календарь чорларына
каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы, муниципаль берәмлек атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар сум/куб.м | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 елның 1 октябреннән алып 31 декабренә кадәр | 2017 елның 1 гыйнвареннән алып 30 июлгә кадәр | 2017 елның 1 июленнән алып 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнвареннән алып 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнвареннән алып 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 31 декабренә кадәр |
| | Норлат муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе* | 100,16 | 100,16 | 104,82 | 104,82 | 108,88 | 108,88 | 115,11 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
26.08.2016 № 10-9/кс
2 карарына кушымта

# Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесенеж җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь ком-плекс оешмасы атамасы | 2016 елның 1 октябреннән 31 декабренә кадәр | | | | | 2017 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәр | | | | | 2018 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәр | | | | | 2019 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) |
| | | Бар-лы-гы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лы-гы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лыгы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лы-гы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | |
| 1 | «Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесе | 62,75 | 44,30 | 3,36 | 15,08 | 6 284,43 | 62,75 | 44,30 | 3,36 | 15,08 | 6 430,83 | 62,75 | 44,30 | 3,36 | 15,08 | 6 704,48 | 62,75 | 44,30 | 3,36 | 15,08 | 6 975,48 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге